ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.12.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 4215**

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү бәясенең чик күләмнәре турында

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балансланган кайнар туклану нормаларын тәэмин итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү бәясенең чик күләмнәре түбәндәгечә билгеләргә:
   - башлангыч сыйныф укучылары өчен иртәнге кайнар аш 66 сум 76 тиен, шуның 66 сумы 76 тиен - субсидия;
   - югары сыйныф укучылары өчен иртәнге кайнар аш бәясе 81 сум 20 тиен, шуның 72 сумы 00 тиен - ата-ана түләве, 9 сум 20 тиен - субсидия;
   - югары сыйныф укучылары өчен ирекле сайлау менюсы (швед өстәле) 99 сум 20 тиен, шуның 90 сумы 00 тиен - ата-ана түләве, 9 сум 20 тиен- субсидия;
   - «Азык - төлек һәм социаль туклану департаменты» АҖ тарафыннан хезмәт күрсәтелә торган гомуми белем бирү оешмаларының югары сыйныф укучылары өчен ирекле сайлау менюсы 66 сум 76 тиен, шуның 57 сум 56 тиен - ата-аналар түләве, 9 сум 20 тиен-субсидия.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 29 декабрендәге «Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү бәясенең чик күләмнәре турында» 3598 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар 2024 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җитәкчесе урынбасары -Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин